

**Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав – Толымбай урта гомуми белем мәктәбе”**

**Кутдусова Венера Хәбир кызы –**

**I квалификацияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы**



# Дәреснең темасы



# “Җыр – кешенең юлдашы”



# ДӘРЕСНЕҢ МАКСАТЫ

**Максат.** ***Укучыларның алган белемнәрен камилләштерү; монологик сөйләм күнекмәләрен, логик фикерләү сәләтен үстерү, эзлекле сөйләмне камилләштерү. Балаларның бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү, сүз байлыгын арттыру, җыр сәнгатенә мәхәббәт хисе тәрбияләү.***

# Дәреснең тибы

**Бәйләнешле сөйләм**


**үстерү**



**Бурычлар**: **татар халык җырлары турында укучыларның белемнәрен киңәйтү, сәнгатьле уку һәм моңлы җырлау күнекмәләрен булдыру, халык иҗатына мәхәббәт тәрбияләү; һәр укучыга шәхси якын килү; төркемдә эшләү күнекмәләрен үстерү; укучыларда югары әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү һәм эстетик тәрбия бирү**

# ҖИҺАЗЛАУ

1. Дәреслек.
2. Сүзлек.
3. Өстәмә әдәбият.
4. Магнитофон.
5. Карточка
6. Компьютер
7. Китап күргәзмәсе



# ДӘРЕСТӘ КУЛЛАНЫЛГАН МЕТОД ҺӘМ АЛЫМНАР

***Сүзлек белән эшләү, презентация күрсәтү, әңгәмә, сорауларга җавап бирү, карточкалар белән эшләү, эпиграфлар барлау, кроссворд чишү һ.б.***

# ДӘРЕСНЕҢ ЭПИГРАФЫ

*Бары да үтә,*
*Бары да онытыла.*
*Байлык, зурлык китә, югала...*
*Тик җыр үлми*
*Күчеп буыннарга*
*Киләчәктә яшәп җыр кала.*

С. Хәким.



# ДӘРЕС БАРЫШЫ

I. Оештыру. Дәрескә хәзерлекләрен тикшерү

Психологик уңай халәт тудыру.

*Якты чырай, якты кәеф*

*Күрәм мин йөзегездә.*

*Исәнмесез, хәерле көн,*

*Телим мин һәммәгезгә.*

II. Үткән белемнәрен актуальләштерү

Проблемалы ситуация тудыру, проблеманы формалаштыру.

1. Өй эшен тикшерү
2. Сорауларга җавап бирү

FedotoVA

# III. Яңа теманы формалаштыру.

1. Уку мәсьәләсен кую.

Укытучы. Балалар, бүгенге дәресебезнең эпиграфы белән танышыйк әле.(эпиграф укыла). - Бу шигырь юлларында нәрсә турында сүз бара?

Укучы җавабы. ( Җыр турында, аның киләчәктә яшәп калуы турында.)

Укытучы. Нәрсә ул җыр?

Укучы җавабы. Көйгә салынган шигъри әсәрләрне җыр дип йөртәләр.

Укытучы. Җыр кайчан туа?

Укучы җавабы. Җыр туа, җыр яши, җырлаучысы булганда – җыр мәңге яши. Җыр ул – яшәү чарасы. Җыр – ул халыкның җаны. Үзенең теле булмаган халык булмаган кебек, үзенең җыры, музыкасы һәм музыка уен-кораллары булмаган халык та дөньяда юк.

FedotoVA

**Укытучы.** Татар балаларының беренче җыр “укытучылары” – аларның әниләре һәм әбиләре. Бишек җырлары үз халкының музыкаль теле турында беренче тәэсирләрне бирә. Ул җырлар яшь балаларны карау вакытында өлкәнрәк балалар тарафыннан да башкарыла. Бишек җыры репертуарларының бай булуы, аларны иҗат итүчеләрнең зур иҗади диапазонлы булуын күрсәтә.

“*Бишек*” җыры яңгырый.

**Укытучы**.Укучылар, күзләрегезне йомыгыз да, әкрен генә моң дәрьясына күмелегез. Татар халкының моңлы, күңел кыллырын тибрәндерүче озын, матур көе безне хис дөньясына алып кереп китә. Халкыбыз яхшы күңелле, ягымлы кешеләр белән горурлана. Элек-электән үк борынгы бабаларыбыз балаларын яхшы гамәлләр генә кылырга, өлкәннәрне хөрмәт итәргә өйрәткән. Алар бер-берсеннән күңел җылысын кызганмыйча, үзара ярдәмләшеп, тату гомер иткәннәр. Әйдәгез әле, сез дә бер-берегезгә күңел җылысы – елмаю бүләк итегез. (*Укучылыр бер-берсенә карап елмаялар).*



**<u>Укытучы</u>**. Укучылар, җыр турында шагыйрь Ф. Яруллин менә болай дигән:

Җыр — кешенең юлдашы,
Җырлый алу бик яхшы.
Берәү җырлый эшендә.
Берәү җырлый төшендә.
Берәү күңеле тулганда,
Берәү эше уңганда.
Берәү җырлый куанып,
Берәү җырлый оялып.
Берәү җырлый хис белән,
Берәү җырлый көч белән.
Ничек кенә булса да,
Начар түгел моңаю.
Җырлый белмәгән кеше
Бәхетсездер, мөгаен.

**Укытучы.** Укучылар, бу шигъри юллар аша шагыйрь безгә нәрсә әйтергә теләгән?

**Укучы җавабы**. Бүгенге көндә җырчылар бик күп. Ләкин моңлы җыр сузучылар гына аз. Шуңа күрә дә Ф. Яруллин “...берәү җырлый көч белән” дигән.

**Укучы җавабы**. Бөтен кешедә дә сәхнәгә чыгып җырлый алмый. Кемдер ояла, кемнеңдер вакыты җитми. Ә кайберләре үзләре өчен генә җырлый, моңлана.

**Укытучы**. Авылыбыздан чыккан җырчы - артистлардан кемнәрне атар идегез?

**Укучы җавабы.** Р. Таҗетдинова, Р. Латыйпов, театр артисты С. Мифтахов, Р. Садриев, Ф. Садриев, Р. Шәрәпов.











**Укучы җавабы.** **Бүгенге көндә авылыбыз мәдәният йорты каршында эшләп килүче “Җырчы сандугачлар” хор түгәрәге һәм “Сердәш” фольклор ансамблендә җырлап йөрүче җырчыларыбыз – сәхнә ветераннары – *Ф. Кутдусов, С. Хәйруллина, А. Измайлов, Ф. Сәләхиева, И. Гатауллин* һ. б. атап үтәргә була.**

**Укучы җавабы.** **Җырчы Ф. Кутдусов инде берничә мәртәбә Казан шәһәрендә үткәрелүче “Җырлыйк әле” тапшыруында да җырлады.** ***Җырчы башкаруында “Яшь гомер” җырын тыңлау.***



**Татар халык җырлары, гадәттә, дүрт төркемгә бүлеп күзәтелә:**

1. Йола һәм уен-бию җырлары.
2. Тарихи җырлар.
3. Лирик озын җырлар.
4. Кыска җырлар.



## IV. Белем һәм күнекмәләрен ныгыту.

Укытучы. Әйтегез әле, без үткән кайсы әсәрләрдә җыр турында искә алынды?

Укучы җавабы. Ф. Кәримнең “Үлем уены”, “Гармунчы аю белән җырчы маймыл”, Н. Исәнбәтнең “Син сазыңны уйнадың” һ. б.

Укытучы. Җыр турында нинди мәкальләр беләсез?

Укучы җавабы.

- Ил яшәве – җыр белән.
- Сүз – басу, җыр – чәчәк.
- Җыр белгәнгә җыр – һөнәр, җыр белү дә – зур һөнәр.
- Бер йөрәктә туган җыр мең йөрәкне кузгата.
- Ай белән көн уртак, җыр белән көй уртак.
- Яхшы җырның даны үзеннән алда йөри.

**V. Физкультминутка**

**Укытучы.** **Әйдәгеә әле, укучылар дәфтәрләрдә эшләп алабыз. Мин биргән карточкалардан үзегезгә ошаган 3-4 мәкальне язып алабыз.**


***Магнитофон тасмасыннан Ф. Борһанов иҗат иткән“Толымбай” җыры яңгырый.***

**Укытучы**. **Мин сезгә карточкалар эләшеп чыктым. Сез андагы кроссвордка күз йөртеп чыгыгыз, һәм аны чишегез. Русча бирелгән музыка коралларын татарчага тәрҗемә итеп язарга. Аерып бирелгән баганада яңа сүзләр килеп чыгарга тиеш.**

***Укучылар кроссворд чишәләр. Бу вакытта магнитофоннан сәхнә ветераны, элеккеге укытучыбыз С. Хәйруллина җыры яңгырый***.



1. Гармонь – гармун;
2. Сорнай (трехструнный щипковый инструмент) – сорнай;
3. Ботало – кыңгырау;
4. Комуз (губной музыкальный инструмент) – кубыз;
5. Гусли – гөслә;
6. Дудка (из полого стебля растений) – курай.







**Курай - курай, дудка (из полого стебля растений)**



**Гөслә - гусли**

**Кыңгырау – ботало**





**Кубыз - комуз (губной музыкальный инструмент)**



**. Гармонь – гармун**

**Сорнай - сорнай (трехструнный щипковый инструмент)**


Укытучы. Кроссвордның дөреслеген тикшерәбез. Халкыбыз көйләренең сихри тәэсир көче-аның моңында. Ә нәрсә соң ул моң?
Сүзлек эше. Моң, көй, төшенчәсенә аңлатма бирү.
Укытучы. Татар халык җырларын иң оста башкаручы артистлар дип кемнәрне саныйсыз?

# Укучы жавабы



И. Шакиров



З. Сәхәбиева



Х. Тимергалиева



Р. Ильясов



Ә. Афзалова



С. Фәтхетдинов



Р. Закиров



З. Шәрифуллина

**Укытучы.** **Халык жырларына нигезләнеп күп кенә композиторларыбыз профессиональ көйләр язганнар : С. Сәйдәшев, Ә. Бакиров, Н. Җиһанов, М. Мозаффаров, А. Ключарев, һ.б.**












***Җыр тыңлау*.**

**Укытучы. Күңелләрне айкый,уйландыра,хисләндерә торган мәгънәле көй бу. Яшьләребез шушындый көйләрне тыңлап үссәләр, ата- анага, дуска-туганга, туган җиргә, туган телгә мәхәббәтләре беркайчан да саекмас иде.**

# VI. Өй эше

“Җыр – кешенең юлдашы” темасына сочинение язу өчен материал туплап килергә

# VII. йомгаклау.

**Җыр – кешенең балачагыннан алып соңгы гомеренә кадәр аерылмас юлдашы. Җыр яраткан кеше матурлыкны ярата. Ул нечкә күңелле, мәрхәмәтле була. Ә нечкә күңелле, матурлыкны яраткан кеше беркайчан да начарлык эшләми. Ул кешеләрне ярата, чит җирләрдә яшәгәндә дә туган ягын сагынып яши, йомшак бәгырьле кешеләргә ярдәмчел, мәрхәмәтле була.**

Татар халкы моңнан яралган,
Керсез хисен көйгә салалган.
Мәхәббәттән илһам алалган,
Җырлап туймас дастаннары калган.
Татар халкы моңнан яралган!

Татар халкы моңнан яралган,
Дөнья буйлап татар таралган.
Тайгасында кала салган,
Илсез калган – телсез калмаган,
Татар халкы моңнан яралган.

